Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы МБГБУ
«Апаз урта гомуми белем мәктәбе»




# “Татар теле – туган телем” телеграм каналында

Проектның авторы: 11 нче сыйныф укучысы
Хәмидуллина Камилә Ринат кызы
Җитәкчесе:Фәйзиева Алсу Вазих кызы



# Гипотеза

Минемчә, яшьтәшләрнең күңеленә юл салу, татар теле туган телебезгә мөнәсәбәтләрен үзгәртүдә заманча технологияләр ярдәм итә алачак.

**Проектның төп максаты:**

Татар теленә карата кызыксыну уяту һәм аны өйрәнүгә мотивлаштыру максатында яшьтәшләремдә кызыксыну уятырлык һәм татар телен өйрәнүгә ярдәм итәрлек мәйданчык эшләү.




**Бурычлар:**

- интернет киңлекләрдә булган татар сайтларын анализлау, өйрәнү;

- өйрәнүләрдән чыгып үземнең каналымны булдыру;

- әлеге каналда татар теленә кызыксыну уятучы, телнең мөмкинлекләрен, камиллеген күрсәтүче мәгълүмат бирү;

- мәгълүматны кыска видеолар, кыска текстлар ярдәмендә тәкъдим итү;


- мәгълүматның грамоталыгына җаваплы карау;

Татар телен үстерү, саклау мәсьәләләренә кагылышлы төрле чаралар еш уздырыла.

**«Татар сүзе»** проекты иң дәрәҗәле, отышлы проект.

Әдәбият сөюче, туган телен хөрмәт итүче, зур максатлар куеп алга баручы, заманча карашлы интернет-кулланучылар арасында иң мөһим проектларның берсе - **#ӘДӘБИМАРАФОН** проекты зур урын алып тора.




Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы
Татар телен һәм Татарстан Республикасында
яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен
саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе
«Татарстан – Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе

ТНВ

ТАТАР СҮЗЕ

РӘХМӘТ ХАТЫ

ХӨРМӘТЛЕ

КАМИЛӘ ХӘМИДУЛЛИНА

«ТАТАР СҮЗЕ» дүртенче Халыкара нәфис сүз
телевизион бәйгесендә катнашып,
туган телебезнең кадерен белеп,
әдәби мирасны саклауда өлеш керткән
өчен олы рәхмәтебезне җиткерәбез.
Сезгә имин тормыш һәм иҗади уңышлар телибез!

Жюри рәисе, Татарстан Республикасы
Язучылар берлеге рәисе
Ркаил Зәйдулла

Казан – 2024


ТАТНЕТНЫ
ҮСТЕРҮ ФОНДЫ

ДИПЛОМ

XXV Дөньякүләм
#әдәбимарафон

татарча китап укучылар онлайн марафонында
актив катнашкан

Хәмидуллина Камилә Ринат кызы

финалист дипломы белән бүләкләнә

Татнетны үстерү фондының
башкаручы директоры
Раил Гатауллин

Татарстан Язучылар
берлеге рәисе
Ркаил Зәйдулла

ID 113

2023

https://tt.wikipedia.org/wiki/Люция_Хәсәнова

tt.wikipedia.org Люция Хәсәнова — Wikipedia пересказать перевести

# Люция Хәсәнова

Телләр өстәү

Эчтәлек яшерү


Башы
Тәрҗемәи хәле
Җырлары
Укучылары
Әдәбият
Искәрмәләр


Мәкалә Бәхәс Укырга Үзгәртү Вики-текстны үзгәртү Тарихын карау Кораллар

**Люция Хәсәнова**
Туган 3 июнь 1951 (72 яшь)
Хәсәншәех, Балтач районы, Татарстан АССР, РСФСР, СССР

**Люция Бари кызы Хәсәнова –** җырчы, Татарстанның атказанган артисткасы (1986).

## Тәрҗемәи хәле [ үзгәртү | вики-текстны үзгәртү ]

1951 нче елның 3 июнендә ТАССР Арча районы Хәсәншәех авылында туа. Кечкенәдән үк җырларга ярата. Районда, мәктәптә үткән җыр бәйгеләрендә катнашмыйча калмый. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, Татарстан җыр һәм бию ансамбленә кабул ителә. Анда эшләгән елларда Урта Азиядә, Себердә, Балтыйк буе республикаларында, Русиянең күп кенә шәһәрләрендә була.

1970 нче елда, Ленинград мәдәният институтының Казан филиалы ачылгач, ансамбльнең хор җитәкчесе Җ. Котдусов тәкъдиме белән шушы уку йортында белем ала. Люциянең җырлавы анда тагын да камилләшә, дирижерлык һөнәрен дә үзләштерә, вокал белән шөгыльләнә, күп тапкырлар хорда башлап җырлый. Вуз студентлары белән Германиягә бара һәм, татар халык җырларын башкарып, тамашачыны таң калдыра. Университет капелласы белән студентларның Ригада үткән “Ювениус-79” конкурсында катнаша һәм, “Сибелә чәчәк” җырын башкарып, беренче урынны алып кайта.

Люция Хәсәнова Татар дәүләт филармониясенең концерт бригадаларында да эшли. Ул татар җырын яратуы, милли репертуарны белүе һәм югары культуралы башкаруы белән башкалардан аерылып тора, борынгы халык җырларын да, татар-рус композиторлары әсәрләрен дә яратып башкара. Татар композиторларының вокаль-җыр иҗатын актив пропагандалаучыларның берсе дә әле ул. Татар музыкасына нигез салучы С.Сәйдәшев, Ф.Яруллин, Н.Җиһанов, Җ.Фәйзи җырлары һәм романслары җырчының репертуарында зур урын алып тора.

Л.Хәсәнова Татарстан Композиторлар берлеге пленум һәм съездларының концертларында һәрдаим катнашып килә: Рәсәй Композиторлар берлегенең Омскида узган күчмә съездында, Мәскәүдәге пленум концертларында, Йошкар-Ола, Уфа, Чабаксарда уздырылган Идел-Урал композиторларының регионара фестивалендә. Хәзер Люция ханым Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать академиясендә вокал дәресләре бирә. Ул инде бик күп җырчылар әзерләп чыгарды.

Доцент гыйльми дәрәҗәсе ала. 1986 нчы елда Люция Хәсәновага “Татарстанның атказанган артисткасы” дигән мактаулы исем бирелә.

# https://tt.wikipedia.org/wiki/Илназ_Гарипов

tt.wikipedia.org Илназ Гарипов — Wikipedia пересказать перевести

ВикипедиЯ
Ирекле энциклопедия

Wikipedia эчендә эзләү Эзләү

Хисап язмасын төзү Керү

Татар дөньясын баетабыз: Әсәрләр Әсбаплар БелемБазасы Медиа Өзекләр Сүзлек ЮлКүрсәткече Карта Атлас
Проектлар: Нигез мәкаләләр ВикиҖанисәп Эзтабар.tatar Хәтер тактасы Хөрмәт һәм мактау Викине үз итүдә ярдәм
Марафоннар: 10*10*10 ТөбәкАтналыгы МинБезТатар Татар4.0 ВикиЯз
[яшерергә]

## Илназ Гарипов

Телләр өстәү

Мәкалә Бәхәс Укырга Үзгәртү Вики-текстны үзгәртү Тарихын карау Кораллар

**Эчтәлек** яшерү

**Башы**
Биографиясе
Белеме
Музыка өлкәсендә эшчәнлеге
Жырлар:
Музыкаль клиплар:

Илназ Гарипов - автор-башкаручы

Файл:Илназ Гарипов.jpg
Илназ Гарипов - автор-башкаручы 1987 елның 2 ноябрендә Казан шәһәрендә туган

### Биографиясе [ үзгәртү | вики-текстны үзгәртү ]

Гарипов Илназ Искәндәр улы 1987 елның 2 ноябрендә Казан шәһәрендә дөньяга килә. Гаиләләре белән берничә ел Казанда яшәгәч, алар әти-әнисенең туган ягы Арча районы Хәсәншәех авылына кайтып төпләнә. 1 сыйныфка Илназ Хәсәншәех мәктәбенә укырга килә. Мәктәп тарихына актив, тәрбияле укучы, иҗади бәйгеләрдә җиңүче, КВН командасының алыштыргысыз уенчысы буларак кереп кала. Мәктәпне тәмамлагач, ул Арча педагогия көллиятенә укырга керә. Анда музыка укытучысы һөнәрен генә үзләштереп калмый, "Арча егетләре" ансамблендә җырлап-уйнап белем, тәҗрибә туплый. "Арча егетләре" ансамбленең данлыклы җитәкчесе Марсель Фәйзрахмановның биш ел дәвамында ярдәмчесе булып тора. "Арча егетләре" сәхнә өчен, гомумән тәрле яклап кешенең шәхес булып өлгерүенә зур этәргеч бирде",- дип саный Илназ.
Шул ук вакытта "Арча" радиосында "Музыкада кунакта" тапшыруы алып бара.

### Белеме [ үзгәртү | вики-текстны үзгәртү ]

Арча педагогия көллиятен уңышлы тәмамлый, музыка укытучысы белгечлеге ала. Бүгенге көндә ике югары белеме бар: музыка буенча һәм

https://tt.wikipedia.org/wiki/Гөлзадә_Сафиуллина



tt.wikipedia.org Гөлзадә Сафиуллина — Wikipedia

ВикипедиЯ
Ирекле энциклопедия

Wikipedia эчендә эзләү Эзләү

Хисап язмасын төзү Керү

Татар дөньясын баетабыз: Әсәрләр Әсбаплар БелемБазасы Медиа Әзекләр Сүзлек ЮлКүрсәткече Карта Атлас [яшерергә]

Проектлар: Нигез мәкаләләр ВикиҖанисэп Эзтабар.tatar Хәтер тактасы Хөрмәт һәм мактау Викине үз итүдә ярдәм

Марафоннар: 10*10*10 ТәбәкАтналыгы МинБезТатар Татар4.0 ВикиЯз

# Гөлзадә Сафиуллина

1 тел

Эчтәлек яшерү

- Башы
- Тәрҗемәи хәле
- Җәмәгать эшчәнлеге
- Кулланылган әдәбият
- Искәрмәләр
- Сылтамалар
- Моны да карагыз

Мәкалә Бәхәс Укырга Үзгәртү Вики-текстны үзгәртү Тарихын карау Кораллар

*Википедиядә Сафиуллина фамилияле башка кешеләр турында мәкаләләр дә бар.*

**Гөлзадә Гомәр кызы Сафиуллина** — җырчы һәм җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның халык артисткасы. Муса Җәлил премиясе лауреаты.


Гөлзадә Сафиуллина


## Тәрҗемәи хәле [ үзгәртү | вики-текстны үзгәртү ]

Арча районының Шекә авылында 1946 нчы елның 8 сентябрендә туа. 7 нче сыйныфны тәмамлагач, 14 яшеннән фермага сыер савучы булып эшкә урнаша һәм бер үк вакытта Яңа Кенәр кичке яшьләр урта мәктәбен тәмамлый, 1965-1970 нче елларда Казан дәүләт ветеринария институтында укый. Казанда укыган вакытта ук үзешчән сәнгать түгәрәкләренә йөри. Институтны тәмамлагач, яшь белгеч Үзбәкстанга эшкә җибәрелә һәм анда кошчылык фабрикасында ветеринария табибы булып эшли. Анда да ул сәнгатьне ташламый. Ахунбабаев исемендәге мәдәният сараендагы үзешчән сәнгать түгәрәкләрендә катнаша. Үзешчән драма түгәрәген җитәкли. Шул ук вакытта Ташкәнт театр институтының режиссерлык бүлегендә дә укый. Ләкин аны туган яклары тарта. 1973-1980 нче елларда Самар, Ырынбур, Сембер филармонияләрендә нәфис сүз остасы һәм җырчы буларак таныла.

# Ни өчен телеграм-канал?

- ✓ телефон аша эшләү җиңел, минем яшьтәшләр өчен бу әһәмиятле, компьютерга караганда алар телефон аша күбрәк эшли.
- ✓ мәгълүмат урнаштыру өчен дә телеграм канал кулайрак.
- ✓ телеграмда канал алып бару өчен зур ресурслар кирәкми.




KAZAN
2023


АЛМАС




ЙОЛДЫЗЛЫК


ӘТНӘ
ДӘҮЛӘТ
ДРАМА
ТЕАТРЫ
1918-2018




АКЫЛ
QAZAN


АРЧА
БАЛАСЫ



**Нәтиҗәләр:**

- татар телен өйрәнүдә ярдәм итәрлек сайтлар бар. Миңа алар арасыннан belem.ru, tt.wikipedia, suzlek.ru ошады. Мәгълүмат күп, дәресләргә әзерлек вакытында кулланырга мөмкин.

- татарча ярдәмлек эшләү өчен телеграм каналга мөрәҗәгать итеп ялгышмадык. Бүгенге көндә 70 язылучы бар, канал яшьләр, укучылар арасында кызыксыну уятты;

-язылучыларның 65 проценты каналдагы сылтама аша татарча шрифт урнаштырды;

-язылучыларның 84 проценты каналдагы мәгълүматны дәрескә әзерлек өчен файдалы дип тапты.

